ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.06.2024 с.Старое Дрожжаное № 286

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы (31.10.2018 № 965, от 29.12.2018 № 1262, от 06.05.2019 № 380, от 11.07.2019 № 565, от 28.08.2019 № 714, от 02.11.2019 № 1008, от 30.12.2019 № 1278, от 16.04.2020 № 294, от 21.05.2020 № 413, от 01.09.2020 № 772, от 23.10.2020 № 954, от 26.07.2021 № 645, от 06.09.2021 № 821, от 29.10.2021 № 1021, от 30.10.2021 № 1030, от 15.06.2022 № 566, от 22.09.2022 № 1027, 24.06.2024 № 454 ТР МК карары ред.) карарының гамәлдә булуын түбәндәге хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартларына таратырга:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләре;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләре;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы мәгариф оешмаларының гомуми тармак вазыйфалары хезмәткәрләре, җитәкчеләре, белгечләре һәм гомуми тармак һөнәрләре хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле профсоюз органы белән килештереп, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы

муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 24 гыйнварындагы 25 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.Р. Измайлов